СОВЕТ
САРСАК-ОМГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САРСАК-УМГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

02.12.2025 Сарсак-Умга авылы № 4-1

Әгерҗе муниципаль районы Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының 2019 елның 26 ноябрендә кабул ителгән 58-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы «Сарсак-Умга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең бюджет кодексы нигезендә, 2025 елның 21 апрелендә кабул ителгән 84-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм "Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү" Федераль законының 14 һәм 15 нче статьяларына үзгәрешләр кертелү, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе районы прокуратурасының 2025 елның 23 октябрендә кабул ителгән 02-08-01-2025/170 номерлы протестын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1.Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге Советының 2019 елның 26ноябрендә кабул ителгән 58-2 номерлы «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. 30 нчы маддәнең 5 нче өлешендә «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре» сүзләреннән соң «(публичный партнер түләве, капиталь грант күләмендә)» сүзләре белән тулыландырырга;
1.2. 42 нче маддәне тугызынчы пунктны түбәндәге эчтәлек белән

тулыландырырга:
«9. Агымдагы финанс елында бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирүне таләп итә торган суд актларын үтәү (кешеләргә китерелгән зыянны компенсацияләү максатыннан чыгарылган суд актларыннан тыш), суд актында билгеләнгән максатларга туры килгән чыгым статьялары буенча бюджет турындагы закон (карар) белән каралган ассигнованиеләр чикләрендә башкарыла.».

2. Бу карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында, https://agryz.tatarstan.ru веб-адресы буенча интернет челтәрендә урнаштырырга, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Сарсак-Умга авыл җирлегендәге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе
Авыл җирлеге башлыгы Т.С. Николаева